СОВЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.01.2016 г с. Новые Чути № 23

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 февралендәге 70 номерлы «Салих авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында» карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында» Салих авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 8 гыйнварындагы 1 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советы тарафыннан 2016 елның 8 гыйнварындагы "Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында карар нигезендә:

1. 2016 елның 13 мартына Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2016 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 200 (ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- авыл җирлеге территориясен төзекләндерү өчен авыл хуҗалыгы техникасы сатып алу - 81800 сум.

- Ягулык-майлау материаллары сатып алу-15000 сум.

«ӘЙЕ, ЮК".

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Баулы районы сайтының «Район турында» бүлегендә «авыл җирлекләре» бүлекчәсендә урнаштырырга һәм Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Салих авыл җирлеге башлыгы З. С. Галләметдинов